**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОБИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2020 Яңавыл авылы № 9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 декабрендәге 719 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 06 февралендәге 103 номерлы карары, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби исәпкә алу системасы эшләвен тәэмин итү инструкциясен һәм хәрби исәпкә алуны иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе оборона министрының 2014 елның 18 июлендәге 495 номерлы боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты **к а р а р  б и р ә**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Хәрби исәпкә алу буенча җаваплы затның вазыйфаи инструкциясе формасын расларга (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.М.Ногманов